СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваши авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

02.04.2024　　　с. Набережные Моркваши　　　46-263

«Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең
Яр буе Морквашы авылында 2023 елның 6 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар
җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставы, 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы редакциядә) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 06 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 13 апреленә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга.

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 06 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яр буе Морквашы авылы Калуга урамында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау)

«ӘЙЕ»　　　　　　　　«ЮК»

3. Гражданнар җыенын Яр буе Морквашы авылы, Красавин урамы, 40 йорт (Башкарма комитет бинасы) адресы буенча 11.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Җыенны оештыручы итеп Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитетын

билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов